**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарманавылжирлеге**
**423350 Сарманавылы, М.Жэлилур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

24 ноября 2020 года № 14

2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегенең социаль-икътисадый үстерү фаразы турында

«2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).

2. Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман Муниципаль Районы Советы Рәисе

авыл җирлеге башлыгы

муниципаль район башлыгы Ф. М. Хөснуллин

1 нче кушымта

**2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең**

**социаль-икътисадый үсеш фаразы**

| Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Бәя | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | кеше | 7700 | 7700 | 7700 | 7690 | 7675 | 7650 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | | | | | | |
| Эре мөгезле терлекләр саны | баш | 508 | 511 | 515 | 517 | 520 | 523 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | | | | | | |
| Инвестицияләр | мең сум. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | | | | | | |
| Торак тапшыру | кв. м. | 4066 | 2015 | 2009 | 4150 | 2034 | 4091 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | | | | | | |
| Хезмәт өчен түләү фонды | мең сум. | 11047,76 | 11177,30 | 10663,14 | 10449,88 | 11066,42 | 11088,55 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | | | | | | |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум. | 29528,3 | 29272,2 | 28164,7 | 27601,4 | 29192,8 | 29085,5 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 3117 | 3182 | 3155 | 3155 | 3159 | 3177 |
| Эшмәкәрләр саны (КФХ)) | кеше | 7 | 7 | 5 | 5 | 5 | 6 |
| Эшсезләр саны | кеше | 15 | 14 | 16 | 18 | 13 | 16 |

**2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**

**Сарман авыл җирлеге**

**социаль-икътисадый үсеш фаразына**

**аңлатма язуы**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнары статьяларын формалаштыру өчен кирәкле төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2021-2023 еллар чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән 2021-2023 елларга Россия Федерациясе икътисади эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2020 елда көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2021-2023 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен исәпкә алып, 2021-2023 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм дефлятор-индексларны кулланып эшләнде.

2021-2023 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 43,3-46,5 АКШ доллар дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2021 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 70,8 сум, 2022 елда – 73,1 сум дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана. 2023 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 72,4 сум тәшкил итәчәк.

Сарман авыл җирлеге ике торак пункттан тора: Сарман, Яңа Әхмәт.

Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2020 елга халык саны 7690 кеше тәшкил итәчәк, 2021 елга-7675 кеше, 2022 елга-7650 кеше.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖ, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның булган потенциалын һәм үсеш тенденцияләрен, шулай ук «Развитие АПК» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖ, «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ һәм Валиева Р.Р., Фаттахов Я.Н., Мухаметдинов И.Р., Нуриев А.Ф., Закиров Б.А. крестьян-фермер хуҗалыклары эшчәнлеге алып барыла.

Эшмәкәрләр саны 2021 елга 158 кеше тәшкил итәчәк, 2022 елга-159 кеше, 2023 елга- 159 кеше.